ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2021 Олы Кайбыч ав. № 53

«Эшмәкәрлек өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 255 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Эшмәкәрлек өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 255 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион үткәрмичә урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (3 нче кушымта):

1.4. пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 17 июнендәге 170 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) белән;»;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.»;

2.8. пунктны түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

3.4.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр.».

1.1. Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы йөкләрне ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (6 нчы кушымта):

7-9 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау кагыйдәләрен раслау турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалту турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 67 номерлы карары белән;

Россия Транспорт министрлыгының 2019 елның 05 июнендәге 167 номерлы боерыгы белән расланган Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы автомобиль юллары буйлап хәрәкәткә махсус рөхсәт бирү тәртибе (алга таба - Рөхсәт бирү тәртибе) белән;

Россия Транспорт министрлыгының 2020 елның 31 августындагы 343 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль юллары буйлап авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтен оештыруга карата таләпләр белән;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 17 июнендәге 170 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) белән;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров